# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл
авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18.11.2023 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45- ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

«Сез 2024 елда Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тоту, ремонтлау (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре);
- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (чүп чабу, агач һәм куакларны кисү буенча хезмәтләр)

ӘЙЕ КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 54 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, гражданнар җыенда катнашып тавыш биргән гражданнар саны – 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен 37,

«КАРШЫ» позициясе өчен 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2024 елда, Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән, күпбалалы гаиләләрдән тыш яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тоту, ремонтлау (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре);
- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (чүп чабу, агач һәм куакларны кисү буенча хезмәтләр)

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт; Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина